БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 14 » сентябрь 2018 ел № 299

Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында

«Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

Балтач муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә;

Балтач муниципаль районы өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне 3 нче кушымта нигезендә;

Балтач муниципаль районы белем бирү оешмаларының эшчеләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне 4 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган Балтач муниципаль районы белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләмен саклап калу һәм алар тарафыннан шул ук квалификация эшләрен башкару шарты белән, әлеге карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкәндә гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан ким булмаска тиеш дип билгеләргә.

3. Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләренә хезмәткәрләрнең тиешле профсоюз органы белән килештереп түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга:

Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган коллектив шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә әлеге карар белән билгеләнгән хезмәткә түләү системасы гамәлгә кертелгәнчегә кадәр ике айдан да соңга калмыйча хезмәт шартларын үзгәртү турында хәбәр итәргә.

4. "Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында" 2013 елның 13 декабрендәге 241 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарының гамәлдә булуы 2018 елның 1 ноябреннән гомуми белем бирү оешмаларына, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына, һөнәри белем бирү оешмаларына һәм өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларына кагылмый.

5. Әлеге карар 2018 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында (baltasi.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе Р. И. Шакиров